РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Площадь Победы, 4, город Бавлы, 423930

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
Җиңү мәйданы, 4, Баулы шәһәре, 423930

Тел.: (85569) 5-29-50, факс: (85569) 5-38-72. E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru, сайт: www.bavly.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_______________ г. Бавлы №______

Төзекләндерү һәм санитар-экологик
чистартулар буенча икеайлыкны үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.03.2010 №567 карарын үтәү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Баулы шәһәре торак пункты территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру, халыкның экологик куркынычсызлыгына җавап бирерлек хәлгә китерү өчен;

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәре территориясен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр игълан итәргә. ( алга таба - икеайлык)
2. Шәһәр территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен координацияләү һәм оештыру буенча оператив штаб төзү (Кушымта №1).
3.Шәһәр территориясен төзекләндерү, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен үтәүгә контрольне көчәйтү өлешендә муниципаль берәмлекләрнең административ комиссияләре эшен активлаштыру.
4. Су объектларының су саклау зоналарын, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек тапшыру базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, ял итү базасын, бакчачылык җәмгыятьләрен һәм гараж кооперативларын, шәхси торак секторы территорияләрен санитар чистарту, контейнер мәйданчыкларын, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар һәм тукталыш павильоннарын норматив хәлгә китерү буенча чаралар үткәрергә.
5. Каты көнкүреш һәм биологик калдыклар полигоннарын (үләт базларын) тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрергә.

6. Ведомство карамагындагы территорияләрне санитар - экологик чистарту эшенә ирекле рәвештә яшьләрнең (волонтерлык) оешмаларын җәлеп итү.

7. Баулы шәһәрен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча 6,13,20,27 апрель көннәрен шәһәркүләм өмәләр дип игълан итәргә.

8. Атна саен Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча мәгълүмат бирергә: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4 нче йорт, каб. № 25, E-mail: Bavly.Gorispolkom@tatar.ru

9. Шәһәр предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- икеайлыкны үткәрү буенча эш төркемнәрен оештыру;
- заказ һәм юу техникасы эшен оештыру;
- Баулы шәһәренең МКП «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе»нә сулыклардан өзлексез су төяүне оештыру өчен биремнәр кую («Биктерра» ЖЧЖ һәм «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 11 нче Отряды» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең 109 Янгын Часте районында);
- шәхси секторда Баулы шәһәре МКП «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе»нә урам комитетлары катнашында өмәләр оештыру буенча биремрәр кую;
- йортларның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау, ишегалды территорияләрендә өмәләр оештыруны ҖЧҖ «Баулы шәһәре һәм Баулы районы идарәче компаниясе»нә, КБО «Безнең ишегалды» ТМШ(Торак милекчеләре ширкәте)нә, хезмәт күрсәтүче оешмалар, ТОС рәисләре һәм йортлар буенча җаваплы кешеләр белән берлектә эшләүне йөкләү;
- ҖЧҖ «Баулы шәһәре һәм Баулы районы идарәче компаниясе», КБО «Безнең ишегалды» ТМШнә контейнер мәйданчыкларын ремонтлауны билгеләү. "Мехуборка Юго-Восток» ҖЧҖнә санитар нормалар нигезендә контейнерларны норматив халәткә китерү, чүп чыгару һәм полигонның өзлексез эше, керә торган каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортировкалау һәм күмү буенча махсус коммуналь техниканың нәтиҗәле эшен тәэмин итү буенча чара үткәрү;
- «Баулы - Горсервис» МКП, Баулы районы электр челтәрләре (РЭЧ) һәм «Энергосервис» ҖЧҖ тарафыннан урам утларын ремонтлау, урамнарны яктырту баганаларын норматив хәлгә китерү (буяу, агарту, чүп үләннәрен җыештыру) биремен билгеләү.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2 нче кушымта нигезендә төзекләндерү һәм санитар чистарту икеайлыгын үткәрү буенча чаралар планын раслау.

11. Баулы шәһәре территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрне 3 нче кушымта нигезендә беркетүне раслау.

12. «Хезмәткә дан» газетасы редакциясен массакүләм мәгълүмат чараларында территорияләрне төзекләндерү һәм санитар чистарту икеайлыгы кысаларында шәһәрдә үткәрелә торган эшләрне даими яктыртуны тәкъдим итү.

13. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: bavly.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында: pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгару.

14. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Д.Л.Бакиров

Кушымта №1
ТР «Баулы шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе карарына

# Исемлек
## икеайлыкны үткәрү вакытында Баулы шәһәре территорияләренә беркетелгән санитар чистарту буенча җаваплы кешеләр

Д.Л.Бакиров - ТР «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитет җитәкчесе - штаб рәисе;

Ф.Ф. Сабитов - Баулы муниципаль районы инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитеты җитәкчесе штаб рәисе башлыгы урынбасары (килешү буенча)

Комиссия әгъзалары:

Р.И. Хасиятуллина - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Р.М.Шаймарданов - ТР «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге башлыгы;

Д.З.Ганиева - МКУ «БМР ТР Мәгариф бүлеге башлыгы» (килешү буенча);

А.А.Халиуллин - МКУ «БМР Яшьләр эшләре буенча бүлегенең башлыгы» (килешү буенча);

| | |
|---|---|
| А.А. Мухамедов | - Ык буе территориаль идарәсенең 3 разрядлы белгече (килешү буенча); |
| Р.Р.Ахунов | - Баулы шәһәре КФП«Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе буенча» директоры (килешү буенча); |
| Г.Г. Алатарева | - Татарстан Республикасы буенча Баулы районы һәм Баулы шәһәре Роспотребнадзор территориаль бүлеге Идарәсенең баш дәүләт санитар табибы (килешү буенча); |
| Р.А. Хабибуллин | - ЖЧЖ нең «Баулы шәһәре һәм Баулы районы Идарәче компания директоры» (килешү буенча); |
| А.К.Альтапов | - ТСЖ «Безнең ишегалды» рәисе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| И.А. Галеев | - «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 11 нче Отряды» ФДБУ 109 ЯЧ башлыгы (килешү буенча); |
| М.Г. Абдуллин | - НГДУ «Баулынефть» идарәсе гомуми әсьәләләр буенча башлык урынбасары (килешү буенча); |
| Р.Ф. Галиев | - Баулы районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең ЮХИДИ бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| М.В.Бикбулатов | - ДКУ «Баулы урманчылыгы» җитәкчесе (килешү буенча); |
| И.Ч. Асадуллин | - Баулы шәһәрендә ЖЧЖ "Мехуборка Юго – «Восток» юнәлеш җитәкчесе, ЖЧЖ «Гринта» вәкиле (килешү буенча); |
| Ахметзянов С.М. | - "Хезмәткә дан» газетасы редакциясе мөхәррире "БРТ" телерадиокомпаниясе «ДУ» директоры (килешү буенча); |

Commented [CP1]:

Кушымта №2
ТР «Баулы шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе карарына

# 2019 елның апрель-май айларында санитар чистарту һәм төзекләндерү икеайлыгын әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планы

| № п/п | Чаралар исеме | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Штаб утырышы үткәрү | 01.04.2019, 01.05.2019 кадәр | Д.Л.Бакиров |
| 2. | Предприятие һәм оешма җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрү. | 01.04.2019, 15.04.2019, 13.05.2019 кадәр | Д.Л.Бакиров, Ф.Ф.Сабитов (килешү буенча) |
| 3. | Иске агачларны кисү, куаклар һәм агачларны декоративлау.<br>Урамнарны, шәһәрнең квартал эчендәге территорияләрен чистарту.<br>Төзекләндерү эшләрен оештыру:<br>- юлларны һәм тротуарларны;<br>- йортларның алгы якларын, урамнарны яктырту;<br>- азык-төлек һәм тапшыру базарларын һәм башка сәүдә объектларын ремонтлау | 01.04.2019-12.04.2019 (һава шартлары буенча) | Д.Л.Бакиров<br>Ф.Ф.Сабитов (килешү буенча)<br>Р.И.Хасиятуллина (килешү буенча)<br>Р.А.Хабибуллин (килешү буенча)<br>А.К.Альтапов (килешү буенча)<br>З.Х.Салахов (килешү буенча) |
| 4. | Беркетелгән территорияләрдә урамнарны юуны оештыру | 15.04.2019-27.04.2019 (һава шартлары буенча) | Д.Л.Бакиров<br>М.Г. Абдуллин (килешү буенча)<br>Р.Ф.Галиев (килешү буенча)<br>Р.Р.Ахунов ( килешү бунча)<br>И.А. Галеев (килешү буенча) |
| 5. | Бордюрларны, юлларны, тротуарларны, урамнарны, ишегалларын төзекләндерү элементларын буяуны оештыру. | 27.04.2019 кадәр (һава шартлары буенча) | Д.Л.Бакиров<br>Р.А.Хабибуллин (килешү буенча)<br>Р.Р.Ахунов |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | (килешү буенча)<br>А.К.Альтапов<br>(килешү буенча) |
| 6. | Баулы шәһәре территориясендә агач һәм куаклар утыртуны оештыру | апрель-май 2019 | Д.Л.Бакиров<br>Р.И.Хасиятуллина<br>(килешү буенча)<br>М.В.Бикбулатов<br>(килешү буенча)<br>А.А.Мухамедов<br>(килешү буенча)<br>Р.Р. Ахунов<br>(килешү буенча)<br>И.А.Галеев<br>(килешү буенча) |
| 7. | Баулы шәһәре стеллаларын һәм Баулы муниципаль районының керү стеллаларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча эшне оештыру | 22.04.2019-07.05.2019 | Д.Л.Бакиров<br>Ф.Ф. Сабитов<br>(килешү буенча)<br>Р.И. Хасиятуллина<br>(килешү буенча) |
| 8. | Өмәләр оештыру, чишмәләрне саклау һәм төзекләндерү | 13.05.2019-16.05.2019 | Д.Л.Бакиров<br>Р.И.Хасиятуллина<br>(килешү буенча)<br>И.В.Саетова<br>(килешү буенча)<br>Г.Г. Алатарева<br>(килешү буенча) |
| 9. | Баулы елгасы ярларын чистартуны оештыру; Баулы шәһәре зиратларын чистартуны оештыру | 20.05.2019-23.05.2019 | Д.Л.Бакиров<br>И.И.Хуснуллина<br>(килешү буенча)<br>Р.М.Шаймарданов<br>Д.З.Ганиева<br>(килешү буенча)<br>Р.Р.Ахунов<br>(килешү буенча) |
| 10. | Балалар мәйданчыкларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү эшен оештыру | 10.05.2019-30.05.2019 | Д.Л.Бакиров<br>И.И.Хуснуллина<br>(килешү буенча)<br>М.Г.Абдуллин<br>(килешү буенча)<br>Р.А. Хабибуллин<br>(килешү буенча)<br>А.К.Альтапов<br>(килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Күп халык ял итә торган урыннарның, бакчачылык һәм урман массивларының санитар торышын контрольдә тоту | икеайлык барышы дәвамында | Г.Г. Алатырева (килешү буенча)<br>А.А. Мухамедов (килешү буенча)<br>М.В.Бикбулатов (килешү буенча)<br>Р.Р. Ахунов (килешү буенча) |
| 12. | Икеайлык кысаларында рейдлар үткәрү | икеайлык барышы дәвамында | А.А.Мухамедов (килешү буенча)<br>Г.Г.Алатырева (килешү буенча)<br>М.В.Бикбулатов (килешү буенча) |
| 13. | Икеайлык барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | икеайлык барышы дәвамында | Ахметзянов С.М. (килешү буенча) |

______________________________